ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.03.2021 п.г.т.Алексеевское № 114

**«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 23 сентябрендәге 735 номерлы башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү хакында**

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 23 сентябрендәге 735 номерлы башкарма комитет карарына кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктындагы b пунктчасының абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм караган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү, аны билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь айда гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып, җан башына уртача керем 20,0 мең сумга кадәр.»;

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В.Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А.Гайнуллин**